**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«29» октябрь 2025 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылы территориясендә яшәүче балигь булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол калган хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: А.И.Борисов

Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов